ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.09.2021 г. Заинск № 543

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә итүне оештыру турында**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чараларын уздыру чорында халыкны сәүдә һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру максатында, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә итүне оештыру турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары Р.М. Архиповага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

М.М. Хәбибуллин
3-41-33

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
03. 09. 2021 ел
543 номерлы карарына
кушымта.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә итүне оештыру турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә итүне оештыру турында әлеге нигезләмә (алга таба - нигезләмә) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә итүне гамәлгә ашырганда, халыкка җәмәгать туклануы һәм күңел ачу хезмәтләре күрсәткәндә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты һәм хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар) арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне, шулай ук стационар булмаган сәүдә, җәмәгать туклануы объектларын, күңел ачу аттракционнарын урнаштыру тәртибен һәм мондый чаралар үткәргәндә (алга таба – күчмә сәүдә) хуҗалык итүче субъектларга карата куела торган таләпләрне җайга сала.

2. Күчмә сәүдә дигәндә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә халыкка җәмәгать туклануы хезмәтләре, күңел ачу хезмәтләре күрсәтү (аттракционнар, батутлар, атларда һәм пониларда йөрү һ.б.) һәм товарлар сату аңлашыла.

3. Участникам выездной торговли торговые места для осуществления деятельности по продаже товаров и оказанию услуг предоставляются безвозмездно. Күчмә сәүдә итүдә катнашучыларга товарлар сату һәм хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен сәүдә урыннары түләүсез бирелә.

## 2. Күчмә сәүдә объектларын урнаштыру һәм аларның эшен оештыру тәртибе

1. Күчмә сәүдә уздыру датасы, урыны, чараны оештыру комитеты составы һәм чараны әзерләү һәм үткәрү планы Башкарма комитетның шәһәр чарасын оештыру һәм уздыру турында карары белән билгеләнә.
2. Күчмә сәүдәне оештыру чараларын Башкарма комитетның икътисад бүлеге гамәлгә ашыра.
3. Башкарма комитетның икътисад бүлеге әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча шәһәр һәм район территориясендә күчмә сәүдә оештыру турында хәбәрнамә әзерләүне гамәлгә ашыра (алга таба - хәбәрнамә).

4. Сәүдә урыннары саны массакүләм чараның масштабын, массакүләм чара үткәрелә торган территория күләмен һәм күчмә сәүдә алып бару өчен Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе килештергән урыннарны исәпкә алып билгеләнә.

5. Күчмә сәүдә өчен әлеге массакүләм чарага билгеләнгән урыннар саны чикләнгән очракта, урыннар җирәбә салу юлы белән бүленә, ул чарага кадәр 3 (өч) көннән дә соңга калмыйча үткәрелә.

6. Тиешле тәртиптә теркәлгән, күчмә сәүдәдә катнашырга теләүче оешмалар, шәхси эшмәкәрләр, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар (алга таба – гариза бирүче) Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә, түбәндәге документларны теркәп, хәбәрнамәгә кушымта нигезендә күчмә сәүдәдә катнашу өчен Башкарма комитет җитәкчесе исеменә гариза җибәрә:

- юридик затлар өчен – юридик зат турында белешмәләрнең юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелү фактын раслаучы документ күчермәләре;
- шәхси эшмәкәрләр өчен - шәхси эшмәкәр турында мәгълүматларның шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертелү фактын раслаучы документ күчермәләре һәм салым органында исәпкә кую турында таныклык;
- «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар өчен - физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә кую турында белешмә күчермәсе.

7. Күчмә сәүдәдә катнашу өчен гаризалар Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган күчмә сәүдәне оештыру турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокларда кабул ителә.

8. Гаризалар күчмә сәүдәдә катнашуга гаризаларны карау комиссиясе тарафыннан карала (әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымта).

Гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча комиссия әлеге нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә сәүдә урыны бирү һәм күчмә сәүдәдә катнашучылар исемлегенә кертү турында, яисә сәүдә урыны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

9. Сәүдә урыны бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) әлеге нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән документларның булмавы;
2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән дөрес булмаган мәгълүмат;
3) кисәтүләр, бозулар, шул исәптән күчмә сәүдә объектын урнаштыру белән бәйле кулланучыларның нигезле шикаятьләре булганда, стационар булмаган объект хуҗасы аларны бетерү буенча чаралар күрә, алай булмаганда объект ябылырга тиеш;
4) тыелган товарлар сату һәм тыелган хезмәтләр күрсәтү күздә тотыла;
5) үз белдеге белән урнаштырылган (күчмә сәүдә объектлары мәйданы буенча арттырылган) һәм схемага туры килми торган объектлар хуҗа көче белән сүтелергә тиеш.

10. Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан расланган күчмә сәүдәдә катнашучылар исемлеге Россия Эчке эшләр министрлыгының Зәй шәһәре буенча идарәсенә һәм "Роспотребнадзор" ның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Әлмәт, Зәй, Лениногорск, Сарман районнарындагы территориаль бүлегенә җибәрелә.

11. Шәһәр һәм район бәйрәм чаралары үткәрү урыннарында күчмә сәүдә объектларын урнаштыру Башкарма комитетның икътисад бүлеге белгечләре схемасы нигезендә башкарыла.

12. Күчмә сәүдә объектларын үз белдегең белән урнаштыру рөхсәт ителми.

## 3. Күчмә сәүдә уздырганда хуҗалык итүче субъектларга карата таләпләр

1. Күчмә сәүдә объектлары заманча эстетик зәвык таләпләренә җавап бирергә һәм чаралар башланырга 1 сәгать кала эшкә әзер булырга тиеш. Сәүдә урыны бәйрәмчә бизәлергә, оешманың фирма исеме, урнашу урыны аның юридик адресы, шулай ук юридик затның исеме, яисә шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) күрсәтелгән элмә такта булырга тиеш. Күчмә сәүдәдә катнашучылар чүп-чар җыю өчен чүп савытлары белән сәүдә урынын тәэмин итәргә, чара үткәрү вакыты дәвамында чүп-чарны полиэтилен пакетларга җыеп, тәртип һәм чисталыкны сакларга тиешләр. Эш тәмамланганнан соң тирә-якны җыештыруны һәм чүп-чарны чыгаруны тәэмин итәргә.

2. Товарлар сату түбәндәгеләр булганда гамәлгә ашырылырга тиеш:

1) сатучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда) күрсәтелгән шәхси карточкасы (бейджы);

2) сатучының шәхесен таныклаучы паспорты яисә башка документы;

3) сатучының күчмә сәүдәдә катнашучы белән хезмәт яки гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләрен раслый торган документы;

4) сатыла торган товарга товар турында документлары;

5) сатыла торган товарларның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслый торган документлары (шул исәптән яраклылык сертификатлары яки декларацияләр, йә аларның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләре, ветеринария таныклыклары, сыйфат таныклыклары);

6) сатучының медицина тикшерүе узуы турында тамгалы шәхси медицина кенәгәсе (азык-төлек товарлары сатканда, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә);

7) санитар киеме (халат, алъяпкыч, перчаткалар, баш киеме);

8) санитар кагыйдәләрне һәм шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәү өчен шартлар (кулъюгыч, сабын, сөлге).

Күрсәтелгән документлар күчмә сәүдәдә товарлар сату (хезмәт күрсәтү) эшчәнлеген гамәлгә ашыруның бөтен вакыты дәвамында сатучыда сакланырга тиеш һәм алар Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда күчмә сәүдәне оештыручы, контрольлек итүче органнар һәм сатып алучылар таләбе буенча күрсәтелә.

3. Товарларны сатканда сатучы кулланучыга товарлар һәм аларны җитештерүчеләр турында ачык һәм аңлаешлы итеп, товарларны дөрес итеп сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә торган тиешле һәм дөрес мәгълүматны җиткерергә бурычлы.

4. Күчмә сәүдәдә сатыла торган товарлар законда билгеләнгән тәртиптә эшләнгән бәя күрсәткечләре белән тәэмин ителергә тиеш.

5. Күчмә сәүдә үткәргәндә түбәндәгеләрне ваклап сату рөхсәт ителми:

- алкоголь продукциясе, сыра һәм сыра нигезендә җитештерелгән эчемлекләр;
- пыяла савыттагы эчемлекләр;
- тәмәке эшләнмәләре.

6. Азык-төлек товарларын ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүче сәүдә урыннары товарлар кую өчен җитәрлек күләмдә лотоклар, бер тапкыр кулланыла торган савыт-саба, төрү материаллары, салфеткалар, ашъяулыклар белән тәэмин ителергә тиеш.

7. Күчмә сәүдәдә товарлар сату (хезмәтләр күрсәтү) буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда катнашучыларның (сатучыларның) бурычлары:

1) халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау, ветеринария өлкәсендә кулланучыларның хокукларын яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү;

2) аерым төр товарларны сатуга куелган таләпләрне үтәү;

3) Россия Федерациясе законнарында каралган башка таләпләрне үтәү;

4) чисталык һәм тәртип саклау, сәүдә урыны янында чүп-чар җыю өчен куелган савытларны вакытында чистарту;

5) предприятиенең профиле һәм махсуслашуы нигезендә азык-төлек продуктларының ассортимент исемлеген үтәү;

6) чара тәмамланганнан соң ике сәгать эчендә сәүдә урынын бушату.

8. Күчмә сәүдә объектын эксплуатацияләү кагыйдәләрен, эшне оештыру тәртибен үтәү өчен җаваплылык гамәлдәге законнар нигезендә күчмә сәүдә объектын урнаштырган оешма җитәкчесенә; шәхси эшмәкәргә; «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затка йөкләнә

Башкарма комитетның
эшләр идарәчесе Т.А. Лоптова

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә итүне оештыру турында нигезләмәгә 1 нче кушымта.

Зәй муниципаль районы территориясендә
күчмә сәүдә оештыру турында
ХӘБӘР

Башкарма комитетның ___________________________________________________________
(аның нигезендә шәһәр чарасы оештырыла торган муниципаль хокукый актның исеме, датасы, номеры)
_______________________________________________________________________________
карарын үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты 202_ елның “__” _____ район территориясендә күчмә сәүдә оештырылуы турында хәбәр итә.

Күчмә сәүдә 202_ елның “__” _____ товарлар сату һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен үткәрелә.

Үткәрү урыны: _____________________________________________________
_______________________________________________________________________________
Күчмә сәүдәнең эш режимы ____ сәгатьтән _____сәгатькә кадәр.

Күчмә сәүдәдә катнашучылар – Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик затлар яисә шәхси эшмәкәрләр, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар.

Гаризалар кабул ителә «__» _________ 20___ елдан «__» _________ 20__ елга кадәр.

Күчмә сәүдәдә катнашучыларга товарлар сату һәм хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген тормышка ашыру өчен сәүдә урыннары түләүсез бирелә.

Сәүдә урыны электр энергиясе белән җиһазландырылмаган.

Башкарма комитет җитәкчесе исеменә гариза «___» __________ 20__ елга кадәр Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Зәй ш., Крупская ур., 6 йорт, әлеге хәбәрнамәгә кушымта нигезендә, түбәндәге документлар теркәп бирелә:

- юридик затлар өчен - юридик зат турында мәгълүматларны юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслаучы документ күчермәсе;

- шәхси эшмәкәрләр өчен - шәхси эшмәкәр турында мәгълүматларны шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслаучы документ, салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәләре;

- «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар өчен - физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә кую турында белешмә күчермәсе.

Гаризалар күчмә сәүдә оештыруга гаризаларны карау буенча комиссия тарафыннан карала.

Комиссия сәүдә урыны бирү һәм күчмә сәүдәдә катнашучылар исемлегенә кертү яки сәүдә урыны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

1.Күчмә сәүдәдә катнашучыларга таләпләр

Күчмә сәүдә объектлары заманча эстетик зәвык таләпләренә җавап бирергә һәм чаралар башланырга 1 сәгать кала эшкә әзер булырга тиеш. Сәүдә урыны бәйрәмчә бизәлергә, оешманың фирма исеме, урнашу урыны аның юридик адресы, шулай ук юридик затның исеме, яисә шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) күрсәтелгән элмә такта булырга тиеш. Күчмә сәүдәдә катнашучылар чүп-чар җыю өчен чүп савытлары белән сәүдә урынын тәэмин итәргә, чара үткәрү вакыты дәвамында чүп-чарны полиэтилен пакетларга җыеп, тәртип һәм чисталыкны сакларга тиешләр.

Эш тәмамланганнан соң тирә-якны җыештыруны һәм чүп-чарны чыгаруны тәэмин итәргә.

1. Товарлар сату түбәндәгеләр булганда гамәлгә ашырылырга тиеш:

1) сатучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда) күрсәтелгән шәхси карточкасы (бейджы);

2) сатучының шәхесен таныклаучы паспорты яисә башка документы;

3) сатучының күчмә сәүдәдә катнашучы белән хезмәт яки гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләрен раслый торган документы;

4) сатыла торган товарга товар турында документлары;

5) сатыла торган товарларның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслый торган документлары (шул исәптән яраклылык сертификатлары яки декларацияләр, йә аларның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләре, ветеринария таныклыклары, сыйфат таныклыклары);

6) сатучының медицина тикшерүе узуы турында тамгалы шәхси медицина кенәгәсе (азык-төлек товарлары сатканда, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә);

7) санитар киеме (халат, алъяпкыч, перчаткалар, баш киеме);

8) санитар кагыйдәләрне һәм шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәү өчен шартлар (кулъюгыч, сабын, сөлге).

Күрсәтелгән документлар күчмә сәүдәдә товарлар сату (хезмәт күрсәтү) эшчәнлеген гамәлгә ашыруның бөтен вакыты дәвамында сатучыда сакланырга тиеш һәм алар Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда күчмә сәүдәне оештыручы, контрольлек итүче органнар һәм сатып алучылар таләбе буенча күрсәтелә.

3. Товарларны сатканда сатучы кулланучыга товарлар һәм аларны җитештерүчеләр турында ачык һәм аңлаешлы итеп, товарларны дөрес итеп сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә торган тиешле һәм дөрес мәгълүматны җиткерергә бурычлы.

4. Күчмә сәүдәдә сатыла торган товарлар законда билгеләнгән тәртиптә эшләнгән бәя күрсәткечләре белән тәэмин ителергә тиеш.

5. Күчмә сәүдә үткәргәндә түбәндәгеләрне ваклап сату рөхсәт ителми:

1) алкоголь продукциясе, сыра һәм сыра нигезендә җитештерелгән эчемлеклә;

2) пыяла савыттагы эчемлекләр;

3) тәмәке эшләнмәләре.

6. Азык-төлек товарларын ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүче сәүдә урыннары товарлар кую өчен җитәрлек күләмдә лотоклар, бер тапкыр кулланыла торган савыт-саба, төрү материаллары, салфеткалар, ашъяулыклар белән тәэмин ителергә тиеш.

7. Күчмә сәүдәдә товарлар сату (хезмәтләр күрсәтү) буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда катнашучылар (сатучылар) бурычлы:

1) халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне сакларга, ветеринария өлкәсендә кулланучыларның хокукларын яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәргә;

2) аерым төр товарларны сатуга куелган таләпләрне үтәргә;

3) Россия Федерациясе законнарында каралган башка таләпләрне үтәргә;

4) чисталык һәм тәртип саклау, сәүдә урыны янында чүп-чар җыю өчен куелган савытларны вакытында чистартырга;

5) предприятиенең профиле һәм махсуслашуы нигезендә азык-төлек продуктларының ассортимент исемлеген үтәргә;

6) чара тәмамланганнан соң ике сәгать эчендә сәүдә урынын бушатырга.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә итүне оештыру турында нигезләмәгә 2 нче кушымта.

Күчмә сәүдәдә катнашу өчен гаризаларны карау комиссиясе составы

| Ф.И.А. | Вазыйфасы |
|---|---|
| Архипова Р.М. | комиссия рәисе, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары |
| Кобелева Е.Н. | комиссия секретаре, Башкарма комитетның икътисад бүлеге баш белгече |
| комиссия әгъзалары: | |
| Хәбибуллин М.М. | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы |
| Чапков А.В. | Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Камалова Р.Н. | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| Садртдинов Р.Р. | Зәй шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Насыйбуллин Р.М. | Роспотребнадзорның ТР (Татарстан) буенча Әлмәт, Зәй, Лениногорск, Сарман районнарындагы территориаль идарәсе башлыгы урынбасары |

Күчмә сәүдә оештыру
турында хәбәргә
кушымта
«____» _________ 20___

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
Э.Э. Галеевка

кемнән____________________________________________________________ (юридик затның исеме, оештыру-хокукый формасы, шәхси эшмәкәрнең, үзмәшгульнең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

____________________________________________________________
(урнашкан урыны, яшәү урыны)

____________________________________________________________
(ИНН)

____________________________________________________________
(җәмәгать туклануы яисә сәүдә предприятиесе төре)

________________________________________________________ элемтә өчен телефоннар

____________________________________________________________
күчмә сәүдәдә катнашуга

ЗАЯВКА

___________________________________________

«___» ____________________20___ ел

Күчмә сәүдәдә катнашучылар исемлегенә кертүегезне һәм хезмәтләр күрсәтү өчен

________________________________________________________________________________ сату өчен сәүдә урыны

(үлчәме кв.м) (кирәкле саны) бирүегезне сорыйм.

___________________________________________________________________ Сатыла торган товарлар ассортименты,

күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге:

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Куркынычсыз хезмәтләр күрсәтү өчен җаваплы (ФИА, телефон) ________________________

________________________________________________________________________________

Товарлар сатуны (хезмәтләр күрсәтүне) оештыруга карата таләпләр белән таныштым.

Имза Дата

МУ

Гаризага терким (кирәклесенә сызарга):

- юридик зат өчен - юридик зат турында мәгълүматларны юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслаучы документ күчермәсе;
- шәхси эшмәкәр өчен – күчермәләр: шәхси эшмәкәр турында мәгълүматларны шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслаучы документ, салым органында исәпкә кую турында таныклык;
- үзмәшгуль өчен- физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә кую турында белешмә күчермәсе

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә итүне оештыру турында нигезләмәгә 3 нче кушымта.

РАСЛЫЙМ

Башкарма комитет
җитәкчесе

_____________Э.Э. Галеев
«____» __________ 20____

______________________________________________________________________________

күчмә сәүдә хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма; шәхси эшмәкәрләр; «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларның исемлеге

Сәүдә итү урыны: _________________

Сәүдә итү көне һәм вакыты: «___» ________20__ ел _____сәгатьтән _____ сәгатькә кадәр

| № п/п | Оешманың исеме (ИП, үзмәшгуль) | Махсуслашуы | Сәүдә урыннары саны |
|---|---|---|---|